**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 10 октябрь | № 731

г. Казань

2017 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга нормативларны, дәвалап бетерү (тернәкләндерү) вакыты дәвамлылыгы нормативларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2017 елга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга хезмәтләр күрсәтү күләмнәрен;

эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга норматив чыгымнарын;

эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерү (тернәкләндерү) вакыты дәвамлылыгы нормативларын.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт учреждениесе (дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга нормативларны, дәвалап бетерү (тернәкләндерү) вакыты дәвамлылыгы нормативларын раслау турында» 2015 ел, 2 октябрь, 735 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\731.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 10 октябрь, 731 нче карары белән расланды

2017 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга хезмәтләр күрсәтү күләмнәре

(кеше)

| Т/с | Оешмалар | Дәвалап бетерүгә (тернәкләндерүгә) җибәрелгән барлык авырулар | Шул исәптән турыдан-туры стационарда дәваланганнан соң | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | кискен миокард инфаркты, стабиль булмаган стенокардия, йөрәккә һәм магистраль кан тамырларында операцияләр | кискен баш мие кан әйләнеше бозылу | умыртка баганасы үсешендә җитешсезлекләр һәм кимчелекләр булганда ортопедик, травматологик операцияләр, буыннар пластикасы, эндопротезлау һәм реэндопротезлау, кул-аякларны реплантацияләү | йөкле хатыннар авырулары, куркынычлык төркеме | шикәр авыруы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1. | Шифаханә-курорт оешмалары | 4 893 | 2 167 | 368 | 117 | 1 923 | 318 |
| 2. | Дәүләтнеке булган медицина оешмалары, шул исәптән: | 657 | - | 603 | 54 | - | - |
| 2.1. | «Сугыш ветераннары өчен госпиталь» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, Чаллы шәһәре | 359 | | 305 | 54 | | |
| 2.2. | «Республика клиник невро- | 298 | | 298 | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | логия үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | | | | | | |
| | Барысы | 5 550 | 2 167 | 971 | 171 | 1 923 | 318 |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 10 октябрь, 731 нче
карары белән расланды

2017 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга
норматив чыгымнары

| Т/с | Дәвалап бетерү (тернәкләндерү) профиле исеме | Норматив чыгымнар, койко-көнгә сум |
|---|---|---|
| 1. | Кискен миокард инфаркты, стабиль булмаган стенокардияне турыдан-туры стационарда дәвалаганнан, йөрәккә һәм магистраль кан тамырларында операцияләрдән соң дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1 192,94 |
| 2. | Кискен баш мие кан әйләнеше бозылуны турыдан-туры стационарда дәвалаганнан соң дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1 187,18 |
| 3. | Умыртка баганасы үсешендә җитешсезлекләр һәм кимчелекләр булганда ортопедик, травматологик операцияләр, буыннар пластикасы, эндопротезлау һәм реэндопротезлау, кул-аякларны реплантацияләүдән соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1 171,86 |
| 4. | Куркынычлык төркемендәге йөкле хатыннар авыруларын турыдан-туры стационарда дәвалаганнан соң дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1169,88 |
| 5. | Шикәр авыруын турыдан-туры стационарда дәвалаганнан соң дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1 166,05 |

_______________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 10 октябрь, 731 нче
карары белән расланды

2017 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерү (тернәкләндерү) вакыты дәвамлылыгы
нормативлары

| Т/с | Дәвалап бетерү (тернәкләндерү) профиле исеме | Дәвалап бетерүнең (тернәкләндерүнең) дәвамлылыгы, календарь көннәр |
|---|---|---|
| 1. | Кискен миокард инфаркты, стабиль булмаган стенокардияне турыдан-туры стационарда дәвалаганнан, йөрәккә һәм магистраль кан тамырларында операцияләрдән соң дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 21 |
| 2. | Кискен баш мие кан әйләнеше бозылуны турыдан-туры стационарда дәвалаганнан соң дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 21 |
| 3. | Умыртка баганасы үсешендә җитешсезлекләр һәм кимчелекләр булганда ортопедик, травматологик операцияләр, буыннар пластикасы, эндопротезлау һәм реэндопротезлау, кул-аякларны реплантацияләүдән соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 21 |
| 4. | Куркынычлык төркемендәге йөкле хатыннар авыруларын турыдан-туры стационарда дәвалаганнан соң дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 21 |
| 5. | Шикәр авыруын турыдан-туры стационарда дәвалаганнан соң дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 21 |

___